БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _______ 2020 ел № ________

**«2020 елга торак урыннан файдаланган өчен түләү (наемга түләү), муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарын карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән милекчеләр өчен торак урыннарын карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен; күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак биналарның милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта капиталь ремонт өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда торак биналарның милекчеләре өчен күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау өчен түләү күләмен раслау турында» 2019 елның 12 октяберендәге 321 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 8.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. «Торак хезмәтләренә тарифлар» кушымтасыннан «Кап. ремонт» графасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов